АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА
им. Г. ИБРАГИМОВА

**Р.К. Рахимова**

# ТАТАРСКО-РУССКИЙ СЛОВАРЬ ЛЕКСИКИ ТКАЧЕСТВА И ШВЕЙНОГО ДЕЛА

Казань
2018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исем.
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

**Р.К. Рәхимова**

# ТАТАРЧА-РУСЧА ТУКУЧЫЛЫК ҺӘМ ТЕГҮЧЕЛЕК АТАМАЛАРЫ СҮЗЛЕГЕ

Казан
2018

**УДК 811.512.145+811.161.1**
**ББК 81.2Тат+81.2Рус**
**Р 96**

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*гыйльми советы карарына нигезләнеп басыла*

**Фәнни редактор**
филология фәннәре кандидаты **О.Н. Галимова**

**Рецезентлар:**
филология фәннәре докторы **Ф.С. Баязитова,**
филология фәннәре кандидаты **И.И. Сабитова**

**Рәхимова Р.К.**
**Р 96** **Татарча-русча тукучылык һәм тегүчелек атамалары сүзлеге.** – Казан: ТӘһСИ, 2018. – 208 б.
ISBN 978-5-93091-259-3

Сүзлеккә тукучылык һәм тегүчелек атамалары – тукыма төрләрен, кием-салым һәм аның өлешләрен, эрләү, туку, тегү коралларын һәм әсбапларын, аларның өлешләрен, тукыма әзерләүдә кулланыла торган үсемлекләр, чималны тукуга әзерләү, бизәкләрне, җепләрне, аларның төрләрен, тегү эшенең төрле стадияләрен атаган 2844 берәмлек теркәлде.

Сүзлек киң катлам укучыларга, аерым тармак белгечләренә тәкъдим ителә.

**УДК 811.512.145+811.161.1**
**ББК 81.2Тат+81.2Рус**

**ISBN 978-5-93091-259-3**

© Рәхимова Р.К., 2018
© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2018

## РЕДАКТОРДАН

Тәкъдим ителгән сүзлеккә телебезнең үзенчәлекле лексикасы теркәлгән. Тегүчелек һәм тукучылык атмалары, билгеле булганча, халкыбызның тарихы, мәдәнияте белән тыгыз бәйләнгән. Алар тегү, туку, тукымалар, кием-салым турында гына түгел, милләтнең дөньяга карашы турындагы мәгълүматны да үзләрендә саклый.

Сүзлек башка традицион терминологик сүзлекләрдән аерылып тора: монда фәнни терминнар түгел, ә халыкта киң таралган һөнәрчелек атамалары теркәлә. Шул сәбәпле сүзлектә атамаларның фонетик, грамматик вариантлары зур урын алып тора, аларның таралу ареалы да җентекләп бирелә. Тегүчелек һәм тукучылыкта предметларның һәрбер элементы, һәр төре дә исемләнгәнгә күрә, бу тармакларның лексикасы терминологик сүзтезмәләргә бай. Мондый берәмлекләр сүзлектә бик киң бирелә. Тәрҗемә өлешендә, һәрвакытта да рус әдәби телендәге эквивалентны биреп булмаганга, тасвирый аңлатмалар, диалектлардан атамалар китерелә. Боларга бәйле рәвештә сүзлек атмаларны теркәү ягыннан терминнары фәнни эшкәртелгән, тиешле дәрәҗәдә оешкан тармак атамаларын туплаган терминологик сүзлекләрдән аерылып тора. Ул һәм терминологик, һәм диалектологик сүзлекләрне төзү принципларына таянып эшләнгән.

Сүзлек ике өлештән тора. Беренче өлештә – тукучылык атамалары, икенчесендә тегүчелек атамалары бирелә. Атамаларны шул рәвешчә бүлеп теркәү бер-берсенә бик якын булган тармакларның һәркайсының үз лексикасын ачыклау максатыннан башкарылды.

Шул рәвешчә, сүзлек халык телендә яшәп килгән бай лексик катламны теркәве, югалып барган атамаларның семантикасын ачып бирүе белән әһәмиятле.

Сүзлек киң катлам укучыларга, тармак белгечләренә тәкъдим ителә.

## СҮЗ БАШЫ

Сүзлеккә татар халкының тукучылык һәм тегүчелек атамалары туплап бирелде. Алар 1965–1980 елларда Татарстан Республикасының төрле район-авылларына оештырылган экспедицияләрдә тукучылардан, өйдә тегү эше белән шөгыльләнүче осталардан, авылдан-авылга йөреп тегүчеләрдән язып алынды. Аерым атамалар Арча, Саба, Балтач, Алексеевск район үзәкләрендә, Казан, Мамадыш шәһәрләрендә урнашкан тегү фабрикаларында эшләүчеләрдән дә тупланды. Сүзлектә халык авыз иҗатында, бигрәк тә җырларда, мәкальәйтемнәрдә, табышмакларда, матур әдәбиятта очраган атамалар да бирелде.

Ярты гасыр элек язып алынган атамалар кул хезмәте чорында барлыкка килгәннәр. Хәзерге вакытта кул һөнәрләрен автоматлаштырылган механизмнар белән эшләү алмаштыра. Икътисади тормыштагы үзгәрешләр, илара сәүдәнең үсүе кешеләрдә әзер кием-салым сатып алу гадәтен барлыкка китерде. Нәтиҗәдә, тукучылык үзенең актуальлеген бөтенләй югалтты. XX гасырның 90 нчы елларыннан ул аерым урыннарда әбиләрдән азмы-күпме өйрәнеп калган хатын-кызлар, һәвәскәр тукучылар тырышлыгы белән милләтнең этнографик үзенчәлекләрен чагылдыра торган күрсәткеч буларак кына яшәп килә. Киемдәге милли үзенчәлекләр дә юкка чыкты. Кешеләр бер үк дәрәҗәдә интернациональ киенә башлады. Мондый үзгәрешләр лексикага да тәэсир итә: тегүчелек атамаларының бер өлеше онытыла, телдән төшеп кала бара. Теге яки бу кием,

предмет кулланышта булса да, атамалар бер төркем халыклар белән уртак булган сүзләр – алынмалар белән алыштырыла. Бүгенге көндә тукучылык һәм тегүчелек атамалары телебезгә *киләп сару, сүс түгел – чүбек, аркавын атсаң, буен алырсың* кебек фразеологик әйтелмәләр, мәкаль-әйтемнәр составында гына килеп керә яисә халык җырларында, табышмакларда, матур әдәбиятта гына очрый:

> ***Тәбәлдерек*** *очкан җеп карынында*
> ***Чабак соса*** *уйнап югала,*
> *Һәм* ***көреләр*** *парлап биеп тора,*
> *Һап та һоп дип* ***кылыч*** *кул чаба.*
> ***Калтырчалар*** *шагор-шогыр җырлап*
> *Җеп чорныйлар курай* ***шүрегә****.*
> *Чыжлап куя* ***чәте чыбыклары***
> *Чытлыкларның уңай җиренә* (Ш. Маннур).

Шул рәвешчә, сүзлекнең актуальлеге, беренчедән, тукучылык һәм тегүчелек лексикасының бай һәм үзенчәлекле булуы (фонетик вариантларның, синонимнарның, төр атамаларының күплеге) белән, икенчедән, әлеге лексик байлыкны саклау һәм киләчәк буынга тапшыру кирәклеге белән аңлатыла.

Тукучылык һәм тегүчелек лексикасы, туку-тегү эшенең үзенчәлегенә, тукылган һәм тегелгән әйберләрнең төрлелегенә бәйле рәвештә, гаять төрле атамаларны берләштерә. Шул сәбәпле сүзлеккә тукучылыкта кулланыла торган үсемлекләр, чималны тукуга әзерләү, туку һәм эрләү кораллары, аларның өлешләре, бизәкләр, җепләр, аларның төрләре, эрләү төрләре һәм туку ысулларының, тукыма, җеп, аларның төрләре, кием-салым, аның өлешләре һәм төрләре, тегү кораллары һәм әсбаплары, аларның өлешләре, тегүче кораллары, аларның өлешләре, тегү эшенең төрле стадияләренең атамалары теркәлде. Өске киемнәрнең тукымадан гына тегелмәвен истә тотып, тире-күн эшләүгә караган кайбер атамаларны да сүзлектә бирдек.

Сүзлек ахырында шартлы кыскартылмалар исемлеге бирелде, чыганаклар күрсәтелде. Туку үрнәкләренең фотолары һәм төрле станнарның рәсемнәре сүзлеккә кушымта итеп бирелде.

Сүзлек Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлегендә эшләнде, лексикография бүлегендә басмага әзерләнде. Сүзлекне техник яктан филология фәннәре кандидаты И.И. Сабитова эшләде.

## СҮЗЛЕКНЕҢ ТӨЗЕЛЕШЕ

1. Баш сүзләр сүзлектә алфавит тәртибендә бирелә. Алар, үзләренә караган материал (рус телендәге эквивалент, аңлатма, иллюстратив мисал) белән бергә, сүзлек мәкаләсен тәшкил итәләр.

2. Бер үк мәгънәдә кулланылган, фонетик яктан гына аерылып торган сүзләр бер мәкалә эченә кертелде, һәм алар ике параллель аша теркәлде. Баш сүз итеп татар әдәби телендә кулланыла торган яисә язма чыганакларга теркәлгән, яки сөйләшләрдә киңрәк таралган атама бирелде. Телдә боларның барысы да очраса, сүзлек мәкаләсендә алар, нигездә, югарыда әйтелгән тәртиптә урнаштырылды.

**ТӘБӘЛДЕРЕК** *Каз.ар.* // **ТАБАЛДЫРЫК** // **ТАБАНДЫРЫК** // **ТӘБӘРЛЕК** *Нор.-Я.Үз.* // **ТӘМӘЛДЕРЕК** *Шәм.-Саб., Килд.-Буа* Подножка, педаль ткацкого стана.

3. Грамматик вариантлар алфавит тәртибендә теркәлде.

4. Терминологик сүзтезмәләр төп сүздән соң алфавит тәртибендә урнаштырылды:

**АСА** («короткий уток» Р.Әхм.) Закладной узор. – *Аса – нечкә җептән, гәрес җептән сугылган бизәк* (Исәнб.-Әг.). – *Аса бизәк кырыйларын чалыштырып атасың.*

**Җепсәле аса** Закладной узор ковра, в местах соединения элементов которого уточные нити на изнаночной стороне перекрещиваются.

**Җепсәләп сугылган аса** *Бикб.-Минз. к.* **җепсәле аса**.

5. Төп сүз, әдәби телдә булып та, тегүчелек терминологиясендә кулланылмаганда, сүзлеккә теркәлмәгәндә, терминологик сүзтезмәләр алфавит тәртибендә бирелде.

6. Атамаларның лексик мәгънәләре нокталы гарәп цифрлары белән аерымланды:

**Баса киндере** 1. Посконь (мужские стебли конопли). 2. Посконный холст, посконина.

7. Омонимнар аерым статьяларда якты рим цифрлары белән билгеләнде:

**ҖӨЙ** I *Каз.ар.* // **ҖҮ** *Ап., О.Тар.-Тәт.* // **ЙҮ** *И.Шәй.-Чүпр.* Шов. – *Җү җүләтергә килгәннәре дә шылай сүлиләр* (О.Тар.-Тәт.).

**ҖӨЙ** II Изделие, работа, шитьё. – *Җөйләрем күбәеп китте, хәзергә заказ алмый торам.*

8. Сөйләм телендәге әйтелеш белән әдәби телдәге язылыш туры килмәгәндә баш сүз квадрат җәяләр эчендә бирелде:

**Самовар бизәк / [самаwыр] бизәк** *О.Әтн.-Әтн.* Браный узор полотенца, напоминающий по внешнему очертанию «самовар».

9. Баш сүздән соң җәяләр эчендә кайбер атамаларның этимологиясе, алынма сүзләрнең чыганагы күрсәтелде:

**НЕЧКӘЗӘР** (Нечкә эзәр) *Остр.Н. к.* **билбау**.

**ПОТМИСКА** (> *рус* **подвязка**) 1. Резинка, резиновая тесьма. 2. Подвязка для подвязывания чулок на ноге.

10. Төп сүздән соң атамалар язып алынган авылларның, районнарның исемнәре күрсәтелде (*к.* кыскартылмалар). Атама бер райондагы берничә авылдан язып алынган булса, авыллар исеменнән соң сызык аша район исеме бирелде. (*Ар.* – Арча / Арск, Арча районы). Мәкаләдәге фонетик вариантлар географик яктан аерылып тормаса, махсус билгеләр барлык вариантлардан соң куелды. Лексик берәмлекләрнең төрле вариантлары төрле ареалларда табылса, географик билгеләр һәркайсыннан соң күрсәтелде:

**АШЛАГА** (> *рус* **обшлаг**) *Кыр.-Әг.* // **ЫШЛАГА** *У.Балт.-Ап., О.Кар.-К.Там.* // **ПЫШЛАГА** *И.Шәй.-Чүпр. к.* **җиң якасы**. – *Каптыра торган пышлага – яшьләргә, каптырмый торганы картларга тегелә.*

11. Татар теле сүзлекләренә теркәлгән, һәркемгә таныш сүзләр янында махсус тамгалар куелмады.

12. Язма чыганаклардан алынган сүзләр янында китапның исеме яисә авторы кыскартылып бирелде. Мәс., Р-II-2 (В.В. Радлов.), К.Нас. (Каюм Насыйри), Остр.Н. (Н. Остроумов).

13. Сүзлектә атамаларның рус телендәге эквивалентын бирү максат итеп куелды. Шул ук вакытта, әлеге катлам лексиканың югалып баруын истә тотып, теге яки бу предметка, тегү технологиясенә хас асыл билгеләрне ачып биргән аңлатмалар китерү дә мөһим дип табылды.

**ВЕЛЮР** (> *фр.*) Велюр; 1. Плотная кожа хромового дубления, которая выработана с мездряной (внутренней) стороны. 2. лучший сорт драпа, бархата, плюша.

Атаманың рус телендә эквиваленты табылмаган очракта тасвирый тәрҗемә яисә җәенке аңлатмалар, рус теле диалектларыннан эквивалентлар китерелде. Диалекталь эквиалентлар калын хәрефләр белән бирелде, аннан җәяләр эчендә диалект яки чыганак күрсәтелде:

**КОЛЫНЧАК** *Бикб.-Минз.* Излишек основной нити, который образуется за тростинками при накидывании в нитчёнки и бердо (ошибка при счёте пасм в процессе снования); **выйма** (*диал. Полесье*).

14. Сүзлек мәкаләсендә тәрҗемә яки русча аңлатмалардан соң *син.* кыскартылмасы белән синонимнар да китерелә:

**КАРЛЫГАЧ КАНАТЫ** *Я.Кен.-Ар.* Меховой воротник с фигурными перегнутыми концами; *син.* **ленинградский яка**.

15. Сүзләрнең мәгънәләре якын булганда да *к.* дип куелды:

**Киҗе җебе** *Исәнб.-Әг.* Хлопчатобумажная, обычно красная, фабричная нить; *к.* **мамык җебе**. – *Чуптарлыда вак көреләр була, чуптары – мамык (киҗе диләрие), гәреч тә бар.*

16. Аерым очракларда атамаларның кулланылыш даирәсен күрсәткән билгеләр дә файдаланылды:

**Киндерне конуслап киптерү** *техн.* Сушка снопов в конусах (снопы ставят, передвигая связку вверх и раздвигая нижние концы, чтобы снопы высыхали равномерно и быстро – в 2–3 дня).

17. Мәгънәне төгәлрәк ачу максатыннан, җанлы сөйләмнән фрагментлар, халык авыз иҗаты һәм матур әдәбияттан үрнәкләр китерелде. Алар рус телендәге эквивалент, яки аңлатмалардан соң тәрҗемә ителмичә сызык ( – ) белән аерылып бирелде:

**АТЛАВЫЧ** *Калм., Бикб., Мәлк.-Минз.* Закладной узор в виде крестовины; «пахтальная мутовка». – *Май яза торган җәпләкәле таяк сыман аталавыч бизәк* (Калм.-Минз.).

18. Баш сүз – ярымкалын баш хәрефләр белән, рус телендәге эквивалентлар яки аңлатмалар – ачык туры хәрефләр белән, иллюстратив материал һәм атамаларның таралу ареалы ачык авыш хәрефләр белән бирелде.

## ТАТАР АЛФАВИТЫ

## ТАТАРСКИЙ АЛФАВИТ

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **Аа** | **Дд** | **Зз** | **Мм** | **Пп** | **Үү** | **Чч** | **ь** |
| **Әә** | **Ее** | **Ии** | **Нн** | **Рр** | **Фф** | **Шш** | **Ээ** |
| **Бб** | **Ёё** | **Йй** | **ң** | **Сс** | **Хх** | **Щщ** | **Юю** |
| **Вв** | **Жж** | **Кк** | **Оо** | **Тт** | **Һһ** | **ъ** | **Яя** |
| **Гг** | **Җҗ** | **Лл** | **Өө** | **Уу** | **Цц** | **Ыы** | |

# ТАТАРЧА-РУСЧА
# ТУКУЧЫЛЫК АТАМАЛАРЫ
# СҮЗЛЕГЕ

**АГАРТУ** Отбеливание пряжи и холста; *к.* **киндер агарту**, **җеп агарту**.

**Җеп агарту** Отбеливание пряжи в зольном отваре (на солнце, на снегу).

**Киләп агарту** *к.* **җеп агарту**.

**Киндер агарту** Отбеливание холста. – *Биек тауда, гөлбакчада Кызлар киндер агарта. Әйтче, сеңлем, конфет бирәм, апаң кемне ярата* (Хал. җыры)?

**АДЫРГА** *Радл.В.* // **АДАРГА** Вороб. *к.* **чәбе чыбыгы**.

**АКСАК ГАРНИТУР** *Бах.-Чист.* Вид холста, вытканного синими и белыми основными нитями.

**АЛАЧА** *Каз.ар., Минз., Нурл., Әг., К.Там.* // **ЫЛАЧА** *Бах. Мөс.-Чист.* Пестрядь; холст, вытканный с нанесением клетчатых или полосатых узоров, образованных переплетением цветных ниток основы и утка; *к.* **бишни**. – *Шакмаклап сукканын – алача, җалан актан гына сукканын киндер дидериек* (О.Кар.- К.Там.). – *Буйга да, аркауга да дүртәр төсле җепне шакмакласаң, шул алача була, күлмәккә. – Элекке кешеләр шул киндерне алача дигәннәр* (Исәнб.-Әг.). – *Суккан нәрсәнең барысын да алача диләр* (Минз.).

**Балалы алача** *К.Бөк.-Б.Бист.* Пестрядь, вытканная красными белыми основными нитями чередованием с одной красной, трёх белых нитей (используется для мужского белья, чаще подштанников.

**Киң юллы алача** Пестрядь с широкими полосами.

**Күкле алача** *Исәнб.-Әг.* Пестрядь с тремя синими и одной белой нитью основы.

**Татар алачасы** *Исәнб.-Әг.* Пестрядь из красных и белых нитей.

**Урыс алачасы** *Исәнб.-Әг.* Пестрядь из синих и белых нитей.

**Чыбык алача** // **Чыбык ылача** *Мөс.-Чист. к.* **юллы алача**.

**Шакмаклы алача** Клетчатая пестрядь, вытканная из разноцветных основных и уточных двухцветными основными нитями.

**Юллы алача** Полосатая пестрядь, вытканная из двух цветных основных нитей.

**АЛҖАПМА** *О.Тар.-Тәт. к.* **алъяпкыч**.

**АЛСУЗМА** *к.* **озын тастымал**.

**АЛЪЯПКЫЧ** // **АЛҖАПКЫЧ** *Каз.ар*. Передник, фартук. *– Синең алларыңда, әй, алъяпкыч, Алларыңда алмалар бармы әллә? Килгәннәрдән бирле карап тордым, Авызыңда былбыллар бармы әллә?* (Хал. җыры)

**Кижеле алҗапкыч** Фартук из домотканого полотна с ткаными узорами браной техники с красными уточными нитями. – *Аркавы, буе җитен җебе, кулдан эрләгән, кызыл җеп кушып суккан, чуар, кып-кызыл бизәкле кижеле алҗапкыч.*

**АРАТА** Поперечина, поперечная планка (палочка), перекладина.

**АРКАУ** *к.* **аркау җеп**.

**АРКАУ ЙӨГЕРТҮ** *Чал.-К.Там., К.Бөк.-Б.Бист. к.* **аркау ату**.

**АРКАУЛЫК** Нить, предназначенная на поперечную нить, подготовленная для утка. – *Миңа яшь булганга аркаулык эрләтәләр, буйлыкны яхшырак итеп әниләр үзләре эрли иде.*

**АТУ** *к.* **аркау ату**.

**Аркау ату** Пропустить уток между продольными нитями. – *Аркавын атсаң, буен алырсың* (Мәкаль).

**АСА** («короткий уток» Р.Әхм.) Закладной узор. – *Аса – нечкә җептән, гәрес җептән сугылган бизәк* (Исәнб.-Әг.). – *Аса бизәк кырыйларын чалыштырып атасың.*

**Җепсәле аса** Закладной узор ковра, в местах соединения элементов которого уточные нити на изнаночной стороне перекрещиваются.

**Җепсәләп сугылган аса** *Бикб.-Минз. к.* **җепсәле аса**.

**АСА ОЯСЫ** Крупный закладной узор ковров. *Аса оялары – төсләре ике иңдә туры китереп сугылган эре-эре бизәкләр.*

**АСА САЛУ** 1. *О.Кар.-К.Там*. Закладка короткого утка для узора. 2. *к.* **кул узу**.

**АСАЛАУ** Тканьё закладным способом, закладное тканьё, закладка (при этом способе для утка берутся разноцветные нити

и уток пропускается не во всю ширину основы, а только там, где должен быть узор. В местах, где уточные нити поворачивают назад, в ткани получается узенькая, почти незаметная щель). – *Асалаганда төрле шүре була. Асалап сукканда да чүплисең җепне. Асалап бетергәч, кагып кына сугасың.*

**АСАЛЫ** С закладным узором. – *Асалы паласка аркау җебен җомгактан гына атасың* (Исәнб.-Әг.). – *Асалы сөлге бик кадерле, кыйммәт була* (Байк.-Ар.). – *Асалы сөлгеләрне әниләр суккан, безгә чүпләм генә туры килде, асалы палас әле дә сугалар* (Сал.-Әг.).

**АТЛАВЫЧ** *Калм., Бикб., Мәлк.-Минз.* Закладной узор в виде крестовины; «пахтальная мутовка». – *Май яза торган җәпләкәле таяк сыман атлавыч бизәк* (Калм.-Минз.).

**АШ** Привар, шлихта, клей; раствор, смесь ржаной муки и воды или молока, в которой кипятят льняные нитки с целью придания прочности и гладкости.

**Җеп ашы** *к.* **аш**.

**АШ ҖАУЛЫГЫ** *Шәле-Пит. к.* **ашъяулык**.

**АШЛАУ** Шлихтование, пропитка основы шлихтой; *к.* **җеп ашлау**.

**Җеп ашлау** *Әтн., Каз.* Шлихтование, обработка ниток в воде или молоке.

**АШЪЯУЛЫК // АШАУЛЫК** *Каз.ар.* Скатерть. – *Ак ашъяулык таптык, Җир өстенә яптык (Кар) (Табышмак). – Өстәл өсләрендә, әй, ашъяулык, Ашъяулык өсләрендә ашамлык. Никләр ашап эчмисез, Сезнең өчен пешкән лә ашамлык?* (Хал. җыры)

**Җөлби ашаулыгы** Скатерть, вытканная в деревне Юльби. – *Җөлби ашаулыгы бик дан, яхшы була.*

**Кижеле ашаулык** *Б.Бист.* Скатерть из красных и синих бумажных ниток в клетку.

**АШЪЯУЛЫК БАШЫ // АШАУЛЫК БАШЫ** Полоска скатерти, получаемая от использования цветных уточных нитей.

**АШЪЯУЛЫК ЧИТЕ // АШАУЛЫК ЧИТЕ** Полоска скатерти, получаемая от использования цветных основных нитей.

**АЮБАШ** *Нор.-Я.Үз., Чүпр. к.* **арткы бавыр агач**.

**АЮБАШ ТАЯГЫ** *Нор.-Я.Үз. к.* **боргыч**.

**АЯЗГА АШАТУ** Отбеливание холста путём расстилания его в мороз на снегу.

**АЯК** *Шәле-Пит. к.* **киләп**. – *Җепне шул аягы белән манабыз.*

**АЯК БАСКЫЧ** *И.Шәй.-Чүпр. к.* **тәбәлдерек**.

**АЯККА КУЮ** Ставить пять или более снопов льна, конопли в копну, прислонив их друг к другу.

**АЯКЛАУ** *Боер.-Минз., Шәле-Пит.* Наматывание ниток широкими кругами в мотки (обычно наматывали на колени, на ноги, на спинки или ножки стульев). – *Җегерләгән, каткан җепне урындык аягына аяклыйсың* (Боер.-Минз.).

**ӘВЕРНӘ** (> әверү, әйләндерү «**крутить**») *Я.Кен., И.Аш.-Ар., Мам., Кук., О.Тар.-Тәт., И.Тинч.-Буа., Үтәг.-Әг.* // **ӘҮНӘ** *Кук., Я.Үз.* Вороб. Вороба, воробы. – *Әвернә белән киләптәге җепне тыбырчага күчереп чолгый торганыек*.

**ӘВЕРНӘ АГАЧЫ** *к.* **әвернә канаты**.

**ӘВЕРНӘ АЯГЫ** Ножки, тренога, подставка вороба (обычно, вместо подставки использовали отрезок ствола дерева с двумя-тремя и более корнями).

**ӘВЕРНӘ КАНАТЫ** *О.Кар.-К.Там.* Крестовина, кресты; две доски, положенные плашмя друг на друга, пересекающиеся под прямым углом и скреплённые неподвижно в центре друг с другом.

**ӘВЕРНӘ КАШЫГЫ** *О.Тар.-Тәт., Ар., Кук., К.Черк.-Буа* Крючки, колышки, веретёна, вороба; палочки, рожки вороба.

**ӘВЕРНӘ ОРЧЫГЫ** *И.Тинч.-Буа к.* **әвернә кашыгы**.

**ӘВЕРНӘ БҮКӘНЕ** // **ӘВЕРНӘ ПҮКӘНЕ** *У.Пош., И.Аш.-Ар., Үтәг.-Әг.* Подставка для вороба.

**ӘВЕРНӘ ТАКТАСЫ** *У.Кирм.-Мам. к.* **әвернә канаты**.

**ӘВЕРНӘ ТӨБЕ** *О.Тар.-Тәт. к.* **әвернә бүкәне**.

**ӘДӘМСӘ** Холст, вытканный в клетку жёлтыми и красными нитями по образцу ткачих из районного посёлка Алексеевск или деревни Адамса. – *Әдәмсәне сары белән кижҗедән шакмаклап сугалар.*

**ӘЙЛӘНМӘ** Круглый тряпичный коврик, вязаный крючком. – *Ыргак белән әйләнмә үрәбез.*

**ӘКӘЙ КАШЫГЫ** *Исәнб.-Әг. к.* **әвернә кашыгы**.

**ӘКӘМ-ТӨКӘМ** *У.Пош.-Ар.* «Улитка»; способ тканья на двух подножках и двух нитченках белыми и синими уточными нитями.

**ӘЛӘКСӘ** *к.* **эдәмсә**. – *Әләксә бездә сукмаганнар.*

**ӘЛЕП САЛУ** Тканьё браным способом, добавляя по одной уточной нити другого цвета, который не пропускается насквозь, а укладывается на определённых участках. – *Әлеп салып сукканда җепне бармакка элеп сикертеп-сикертеп алабыз.*

**БАВЫР АГАЧЫ** *Исәнб.-Әг., О.Тар.-Тәт., Каз.ар.* Полотняный навой, пришва, навивка.

**Арткы бавыр агач** Пряжной навой.

**БАРМАК** *И.Тинч.-Буа к.* **сөрмә**. – *Ашъяулыктагы буй сызыклар бармак була.*

**БАСА** Посконь, дёрганцы, бранцы.

**Киндер басасы** *к.* **баса киндере**.

**БАСА АЛУ** Отбор (на поле) стеблей созревшей поскони от несозревших стеблей семенной конопли-матерки; *к.* **баса йолку**.

**БАСА ҖӘЮ** Расстилание поскони конопли для разложения и удаления вещества, склеивающего волокна между собой и (их со) стеблем (обмолоченные стебли поскони держат на лугу 15–20 дней).

**БАСА ЙОЛКУ** Уборка, дёрганье поскони (после отцветения выбирают мужские стебли конопли среди семенной части конопли и дёргают с корнем).

**БАСМА** Пасмо, пасма (единица измерения длины нитей, мотка), состоящая в разной местности из разного количества чисменок: из 10, 30, 60 и т.д. (по 3 или 4 оборота на мотовиле). *Бах.-Чист., Кадр.-Минз.*: 30 ниток (10 чисменок по 3 оборота на мотовиле); *К.Черк.-Буа*: 90 ниток (30 чисменок по 3 оборота на мотовиле); *Тирс.-Әг., Бик.-Нурл.*: 120 ниток (30 чисменок по 4 оборота на мотовиле); *Үтәг., Исәнб.-Әг., И.Эсл.-К.Там.*: 240 ниток (60 чисменок по 4 оборота на мотовиле) и т.д.

**БАСМА БАВЫ** Пасменщик; толстая нитка, перевязывающая пасмо поперёк.

**БАСМАЛАУ** *Тат.Кар.-К.Там.* Переложение в моток, в пасмо с определённым количеством ниток.

**БАТАН** *Алек.* У механического ткацкого стана: рама для установления берда.

**БАШ** Начало тканья, начальный ряд; край тканины.

**БАШ БӘЙЛӘҮ** *О.Кар., Тат.Кар.-К.Там.* Подготовка к тканью: привязывание концов основных нитей попарно к пруточку, вкладываемому в пришву.

**БАШ ҖАГАЛАГЫЧ** *У.Кирм.-Мам., Шәле-Пит. к.* **җагалау чыбыгы**.

**БАШ ҖАГАЛАУ** *Исәнб.-Әг., Кук.* Привязывание передних концов основы к палочке, прикреплённой к переднему навою пришвы. *Баш җагалау – җеп очларын икешәрләп бавыр агачы ярыгындагы таякка бәйләп кую.*

**БАШ КУЮ** *К.Черк.-Буа, Тат.Кар.-К.Там. к.* **баш җагалау**.

**БАШЛАУ** Начало процесса тканья.

**БАШ ТАЯГЫ** *Саб., Әтн.* 1. Используемый в начале тканья пруток, на который накладываются концы основы для полного их использования (пруток вкладываются в пришву); **затыкач**, **затыкальник** (*диал. Полесье*). 2. *Әтн.* При тканья сита из конских волос: верхняя колочка, к которой привязываются волосы для основы.

**БАШ ЧЫБЫГЫ** *О.Кар.-К.Там,. Тат.Карл.-Буа* Затыкальник.

**БАШ ЭЛҮ** *И.Шәй.-Чүпр. к.* **баш бәйләү**.

**БАШ ЮЛ** *У.Кирм.-Мам. к.* **ашаулык башы**.

**БАШ ЯСАУ** *О.Кар.-К.Там. к.* **баш җагалау**.

**БУЫН** *К.Бөк.-Б.Бист. к.* **күз**.

**БӘБӘК** *Шәле-Пит. к.* **сөрмә**. *– Зәңгәр белән сары арасына кара бәбәк тыгабыз.*

**БӘБӘКЛӘҮ** *К.Әшн.-Б.Бист. к.* **сөрмәләү**. *– Ак белән бәбәкләгән, кызыл белән бәбәкләгән тастымал, ашаулыклар суктык.*

**БӘБКӘ** *Мам.* // **БӘПКӘ** *Тирс.-Әг.* Бабка; копна из 8–10 снопов льна, конопли.

**Җитен бәбкәсе** Бабка, укладка льна из 8 – 10 снопов.

**БӘБКӘГӘ КУЮ** Укладка льняных снопов в копну в виде бабок.

**Җитенне бәбкәгә кую** Кладка снопов льна в бабки для подсушки.

**БӘЛӘК** // [**WӘЛӘК**] (> *рус.* **валек**) *К.Черк.-Буа* Валёк для колочения холста при белении на солнце (окунув холст в воду, его кладут на камень и колотят). – *Киндер җебен wәләк белән суккалап чайкыйсың.*

**Кер бәләге** Бельевой гладкий валёк, используемый при стирке и белении холста.

**Кырлы бәләк** Ребристый валёк (в старину применяли при стирке и раскатывании белья). *Кырлы бәләк белән юган керләрне шомартасың.*

**Сырлы бәләк** *Тирс.-Әг. к.* **кырлы бәләк**.

**БЕР КОЕРЫК** *Килд.-Буа* Холст, тканый одним бердом от начала до конца.

**БЕР ТЕШЛЕК** По одной нити (между двумя тростинами берда. – *Күкне озатып, бер бөртек ак белән җаралар, бер тешлек озаталар* (Бах.-Чист.).

**БЕТЕРГЕЧ** *Мам., К.Бөк.-Б.Бист.* 1. Дотыкальная палочка с дополнительной ниткой для упорядочения основных нитей, вкладываемая в зев при завершении тканья, когда нити уже не входят в нитченки. 2. *Мөс.-Чист.* Последняя уточная нить при завершении тканья.

**БЕТЕРГЕЧ БАВЫ** *Минз. к.* **тәләкә бавы**.

**БЕТЕРГЕЧ ТӘЛӘКӘСЕ** *К.Бөк.-Б.Бист. к.* **бетергеч** 1.

**БЕТЕРҮ** *к.* **киндер бетерү**.

**Киндер бетерү** *Каз.ар.* Завершение процесса тканья.

**БИЕТКЕЧ** *Я.Байл.-Минз.* Палочка-перекладинка с привязанными на концах верёвками, идущими от нитчёнок к потолку (при тканье ковров вручную); **пересмыч**, **покотёльник**, **прутик** (*диал. Полесье*).

**БИЗӘК** *Каз.ар.* Узор, орнамент.

**Аса бизәк** *к.* **аса**.

**Биш калаклы бизәк** Вид простого узора белого полотенца, вытканного браным способом на пяти дощечках.

**Кәкре бизәк** *Я.Кен.-Ар.* «Кривой узор»; зигзагообразное лекало, напоминающее цифру два, для стегания ватных одеял.

**Киртләч бизәк** *к.* **бизәк**.

**Самовар бизәк / [самаwыр] бизәк** *О.Әтн.-Әтн.* Браный узор полотенца, напоминающий по внешнему очертанию «самовар».

**Сөлге бизәге** Узор полотенца.

**Сызык бизәк** *к.* **сөрмә** 2.

**Урынтын бизәк** *И.Кен.-Ар.* Узор островками на одноцветном фоне. – *Чаршауга урынтын бизәкле ситса алдым.*

**БИЗӘКЛЕ** С узором.

**Юл-юл бизәкле** Ткань с полосатым узором.

**БИЛЛЕ ЧӘКӘН** *Тат.Кар.-К.Там.* Узор браного тканья в форме пряников.

**БИСТӘР** *Кадр.-Мөсл., Чист. к.* **тастымал**.

**БИШНИ** 1. *Ар., Бал., Әтн.* // **БИШЕНИ** *Бах.-Чист.* Вишнёвый, фиолетовый цвет. 2. *Шәле-Пит., Бах.-Чист.* Тёмно-синий цвет. *Бишни җеп белән чигү өчен язу карасына манадырыек.* 3. *Шәле-Пит., Бах.-Чист. к.* **алача**. – *Бишни күлмәк биш иң була, Итәген дә бишне сал. Яна йөрәгем китер кар, Кайный бәгърем, куйныңа ал* (Хал. җыры). – *Бишени күлмәк биш төймә, Кигән саен киясем киләдер, Син туганкайның җакты җөзен, Күргән саен күрәсем киләдер* (Хал. җыры).

**Аклы бишни** Пестрядь, тканая с применением белых нитей.

**Күкле бишни** *Шәле-Пит.* Пестрядь с преобладанием синих нитей.

**Сары бишни** *Шәле-Пит.* Пестрядь с преобладанием жёлтых нитей.

**БИЮ** *Бикб.-Минз.* Палочка длиною в 15 см, соединяющая верёвки от нитчёнок стана при тканье ковров; *син.* **көре тияге**, **мыскал бавы**.

**БИЮ БАВЫ** *И.Байл.-Минз.* Верёвки, соединяющие нитчёнок с поперечной перекладиной.

**БИЮ ТАЯГЫ** *Боер.-Минз. к.* **бию**.

**БОРГЫЧ** *Каз.ар., И.Мәң.-Ар.* Притужальник; палочка, используемая для запирания пришвы.

**БОРГЫЧ ТАЯГЫ** *Тат.Кар.-К.Там., Алек., Әлк., О.Тар.-Тәт., Тирс.-Әг. к.* **боргыч**.

**БОРЫС** *Каз.ар.* (> *рус.* **брус**) Полоски скатерти, вытканные по краям цветными нитками утка или основы.

**Баш борысы** Полоска, вытканная цветными уточными нитями; *к.* **ашъяулык башы**.

**Чит борысы** *к.* **ашаулык чите**.

**БӨТИ** // **БЕТИ** *Килд.-Буа* Узор клетками, узор, вытканный закладным способом. – *Ун соса белән дә алсаң, бөти тагын да матуррак була, төрле төстәге бөтиләр була.*

**БУЙ** Длина, продольное направление нитей; нити основы; *к.* **буйлык**.

**Бүрәнә буе** *Саб.* Длина основы для наведения на ткацкий стан (приблизительно в 6–7 м).

**Иреш буй** Длина основы на ткацком станке от пришвы до заднего колышка.

**Киерге буе** *Б.Бист.* Длина на сновальне, пасма (длина сновальни обычно от 2 до 3,2 м или от 3 до 5 м).

**Киләп буе** *У.Пош.-Ар.* Длина пряжи, равная длине мотовила (обычно 4 с половиной аршина). – *Элек бер киләп буеннан биш аршын киндер сугарыек, иртәдән кичкә хәтле, 20 тиенгә.*

**Стена буе** *к.* **бүрәнә буе**.

**БУЙ-БУЙ** *к.* **буйлы**. – *Быел суккан киндерләрем, Буй-буй киткән кара җул. Аерылдык – ни хәл итим, Алла язгач, чара җук* (Хал. җыры) .

**БУЙЛЫ** Полосатый. – *Буйлы сатин. – Буйлы алача.*

**БУЙЛЫК** *Каз.ар., Тау я.* Основа, основная нить, система нитей, составляющих длину ткани и других изделей. – *Киндер буйлыгы. – Чыпта буйлыгы. – Иләк буйлыгы.*

**БУЙЛЫК САРУ** *к.* **буйлык озату**.

**БУЛДЫРУ** *Чал.-К.Там.* Расстилка льна на влажной земле.

**Суда булдыру** Мочка льна на воде.

**Суда чылатып булдыру** *к.* **суда булдыру**

**Чыкка җәеп булдыру** Мочка льна на росе, увлажнение льна.

**Чыкта булдыру** *к.* **чыкка җәеп булдыру**.

**БҮТӘКӘ** *Шәле-Пит. к.* **чүбек**. – *Бүтәкәсен эрләп җәймә сугадырыек: арыш киптерергә, җабынып ятырга, хәзер идәнгә җәябез.*

**ГАРЫС** *Кел.-К .Там., О.Тар.-Тәт.* // **ГӘРӘЧ** *Саб.* // **ГӘРӘС** *К.Бөк.-Б.Бист.* // **ГӘРЕС** // **ГӘРЕЧ** // **КӘРЕС** Гарус; шерстяная нить фабричного производства, обычно для вышивания ворсовым способом.

**Фабрик гарысы** Фабричный гарус; шерстяная пряжа для узорного тканья.

**ГАРЫС ҖИБӘРҮ** *Шәле-Пит.* Использование цветного гаруса для получения линейного узора уточной нитью. – *Эзәр башына, сөлге башына икенче төстәге гарыс җибәрәләр – берничә рәт сызык бизәкләр килеп чыга.*

**ГЕРӘМӘНКӘ** (> *рус.* **гребенка**) *Тат. Кар.-К.Там., Килд.-Буа* // **ГЕРӘБӘНКӘ** *Алп.-Әлк. к.* **тәрәш**.

**ГЫРНАДИР** (> *фр.* **гроденапль** – вид плотной шёлковой ткани). *Бах.-Чист.* Холст, вытканный белыми и синими основными нитями.

**ДИЛБЕГӘ** Полоса, полоска, полосатый узор; *к.* **юл**.

**ДЕБЕТ** // **ТӨБӨТ** Нитка из шерсти тибетских коз.

**ҖАГАЛАУ** *к.* **суга башлау**.

**ҖАГАЛАУ ЧЫБЫГЫ** *Тәб.Чал.-Б.Бист.* Пруток, палочка, прикреплённая к переднему навою пришвы, пропущенная перед началом тканья между завязанными в узел концами основных нитей.

**ЖАККАРД СТАНОГЫ** Жаккардовый станок для крупного узорного двухстороннего тканья.

**ҖӘЙМӘ** // **ЙӘЙМӘ** 1. Простыня; покрывало. 2. *Т.Ур.-Т.Кам., Тат.Нарат., Тау и.-Я.Үз., О.Тар.-Тәт. к.* **ашъяулык**. – *Җәймә чите икенче төрледән ясала. Табын җәймәсе нечкә*

*мамык җептән. – Җәймә кулдан сугыла, эскәтере – сатып алынганы – затлырак энде* (*инде*) (Т.Урыс.-Я.Үз.). – *Табын йәймәсенең* (*җәймәсенең*) *тирәге дә, ние дә юк, шау шакмак.* 3 Напольный коврик, дорожка. – *Кайбер кеше әле дә чүпрәкләрдән идәнгә җәймәләр суга.*

**Идән җәймәсе** *к.* **юллык**.

**Караваt җәймәсе** Простыня.

**Мунча җәймәсе** Банное покрывало.

**Өстәл җәймәсе** Скатерть; *син.* **ашъяулык**.

**Табын җәймәсе** *О.Тар.-Тәт.* Большая скатерть для застолья, скатерть для стола с угощением.

**Түшәк җәймәсе** Простыня (для большой квадратной перины, тюфяка).

**Чәй җәймәсе** *О.Тар.-Тәт.* Маленькая скатерть (по сравнению со скатертью для застолья).

**Чынаяк җәймәсе** Салфетка на посуду.

**Ястык җәймәсе** Простыня (для большой квадратной подушки).

**Ятак җәймәсе** *к.* **карават җәймәсе**.

**ҖӘКЕР** (> *рус.* **якорь**) Узор полотенца браного способа тканья.

**ҖӘНТЕКӘЙ** *Аю-Минз. к* .**бию**.

**ҖЕП // ЕПЬ** (*миш.д.*) Нить, нитка; пряжа.

**Аркау җеп** Уток, уточная нить (поперечные нити пересекаясь с продольными (основными), образуют переплетение (ткань)).

**Ашлаган җеп** Шлихтованная нитка, пряжа (пропитанная раствором из ржаной муки в молоке или воде).

**Аяклы җеп** *Шәле-Пит.* Пряжа, нить, кругами намотанная на спинку стула, на руки, на ноги и т.п. – *Асланчылар аяклы җеп сатып җөриләрие.*

**Базар җебе** *О.Тар.-Тәт.* Фабричная пряжа.

**Балавызлаган җеп** Вощёная нитка.

**Бобин җебе** Нити, намотанные на бобину.

**Буй җеп** *к.* **буйлык җеп**.

**Буйлык җеп** Основная нить, основная пряжа.

**Гәреч җеп** *Исәнб.-Әг. к.* **гарыс**.

**Җиле җебе** // **Җил җебе** *Буа, Әг.* 1. Нитка, завязка, перевязывающая пасмо на месте скрещевания основы на дополнительных колышках (с помощью которых нити описывают восьмерку, разделяя основу на верхние и нижние нити зева). – *Озатканда уртадагы чалышындырудан уздырасың. Җил җебеннән чәбе таягы тыгадыр идек. – Озатып беткәч, уртада кисешкән җиренә җиле җебе тыгып куясың.* 2. *О.Кар.-К.Там., Нурл.* Нитка, перевязывающая моток поперёк до снятия с мотовила и обозначающая концы нитей.

**Җилен җеп** *Тат.Исл.-Я.Үз. к.* **басма бавы**. – *Җилен җеп тыккан урынга ыстанга коргач чәбе тыгыла.*

**Җитен җебе** Льняная нить.

**Ике тешлек җеп** Две нити, пропущенные между двумя тростинками берда. – *Ике тешлек – кылычның һәр теш арасына икешәр бөртек җеп үткәрәбез.*

**Каткан җеп** Сучёная нитка.

**Катмаган җеп** Несучёная нитка.

**Кәтүк җебе** // **Катук җебе** *Килд.-Буа* // **Мәтүк җебе** *И.Тинч., К.Черк.-Буа* Катушечная нитка, используемая как основная нить.

**Кибет җебе** *О.Тар.-Тәт.* Покупная пряжа, фабричная нитка.

**Киҗе җебе** *Исәнб.-Әг.* Хлопчатобумажная, обычно красная, фабричная нить; *к.* **мамык җебе**. – *Чуптарлыда вак көреләр була, чуптары – мамык (киҗе диләрие), гәреч тә бар.*

**Киләпле җеп** Пряжа, нить получаемая при наматывании её на мотовило.

**Киндер җебе** Пеньковая или льняная суровая нить.

**Комач җебе** *О.Тар.-Тәт.* // **Комач йебе** *И.Тинч.-Буа* Красная хлопчатобумажная нитка, фабричного прядения, используемая как основа.

**Көре җебе** Толстая нить, используемая для подготовки петель нитченок.

**Көрчин** (> *рус* **крученая**) **җебе** Трощёная (навитая в две или три нити) хлопчатобумажная нить фабричного прядения. – *Көрчин буйга тартыла (буйлыкка озатыла), киҗе җебе җомшак – буйга җарамый, аркауга китә.*

**Мамык җебе** *И.Тинч.-Буа* Хлопчатобумажная нить.

**Озаткан җеп** *Пәр., Ю.Ыр.-Ла. к.* **буйлык**.

**Озатма җеп** *к.* **буйлык**.

**Пачас җебе** Пряжа из чёсаного льна (употребляется для основы при тканье паласов и т.п.).

**Сүлпән җеп** Нить слабого кручения.

**Сүс җебе** *к.* **киндер җебе**.

**Тамбур җебе** Вышивальная нить, которая использовалась при узорном тканье браным и выборным способах и при вышивании на пяльцах.

**Тегәр җеп** Суровая нить; пряденая вручную льняная нить. – *Тегәр җеп нык була, ул кулдан теккәндә, ямау ямаганда тотыла.*

**Шүрәкә җебе** *Карад.-Ар., Бал.* Катушечная нить, фабричная нить.

**Чалма җебе** Кручёная нить, намотанная в клубок особой формы (типа чалма).

**Чалмалы җеп** *Я.Кыяз.-Акс. к.* **чалма җебе**.

**Чи җеп** Нешлихтованная сырая нить.

**Чирак җеп** Нить крутого сучения, сильно кручёная нить.

**Чүбек җебе** Пряжа пачесная для тканья грубых тканей, торпищ и т.п.

**Чыны җебе** *Алп.-Әлк. к.* **җил җебе**.

**Юл җебе** *к.* **җиле җебе**. – *Юл җебе (җиле җебе) чуалмасын өчен аркылыга буйлык яки киләп җебе бәйләп куела.*

**ҖЕП АТУ** *И.Мәң., Я.Кен., У.Пош.-Ар. к.* **аркау ату**.

**ҖЕПКАТКЫЧ** *Бах.-Чист. к.* **каткыч**.

**ҖЕП КАТЛАУ** *Алек.* Трощение, таращение; перематывание двух ниток с разных клубков в один клубок, подготовка пряжи к кручению; в результате трощения происходит соединение нитей.

**ҖЕПСӘ** I *Ямәк-Минз., Тат.Кар.-К.Там., Килд.-Буа, Кадр.-Минз. к.* **чәбе**. – *Көре керә торган урынга сукканда, җепләр буталмаска, җепсә куела* (Ураз.-Я.Үз.). – *Җепсә көре артына озаткан җеп чуалмасын өчен куела* (Күзк.-Минз.).

**ҖЕПСӘ** II *У.Пош.-Ар., Минз.* Деревянные планки тростей, зажимающие пластинки берда.

**ҖЕПСӘ** III *Болг.-Т.Кам., Саб., Минз.* Пруток. – *Җепсә – шүрене сосага беркетә торган нечкә чыбык.*

**ҖЕП ТАКТАСЫ** *Тәб.Чал.-Б.Бист., Саб. к.* **әвернә тактасы**.

**ҖЕРЛӘҮ** *У.Пош.-Ар.* // **ҖЕГЕРЛӘҮ** *Мам., Саб., Кук. к.* **эрләү**. – *җеп җегерлә, киндер сук, шуннан башка нәрсә юк* (Мәкаль).

**ҖИЛЕ** // **ҖИЛ** Нитка перебора

**Киләп җиле** *к.* **җиле җебе** 2.

**ҖИЛЕ АГАЧЫ** *Боер.-Минз. к.* **чәбе**.

**ҖИЛЕ БАВЫ** *Бикб.-Минз. к.* **җил җебе**. – *Озаткач, җепнең башына, чобалмас өченгә җиле бавы куела. Көрегә җиледән бирелә.*

**ҖИЛЕ ТАЯГЫ** // **ҖИЛ ТАЯГЫ** *О.Тар.-Тәт. к.* **чәбе таягы**.

**ҖИЛЕ ЧӨЕ** // **ҖИЛ ЧӨЕ** Средние две колышки сновалки, на которых образуются чины (на месте скрещивания нитей при сновании на этих колышках, на ткацком стане пропускаются цены или ценовые палочки).

**ҖИЛЕН** *Тат.Исл., Мулл.-Я.Үз. к.* **җиле җебе**. – *Озаткач җиленгә җеп тыкмасаң, чобала. – Көре артында җилен булмаса, сугып булмый. – Җилен җебен тыккан урынга, станга коргач, чәбе тыгыла.*

**ҖИТЕН** Лён.

**Озын сабаклы җитен** Лён-долгунец.

**ҖИТЕН АЛУ** Дёргать, теребить лён; убирать с поля, вырывая с корнями.

**ҖИТЕН БАШЫ** *К.Ел.-Ла.* Головка льна с семенами. – *Йолыккач, җитеннең башын сугып аласың.*

**ҖИТЕН БУЛГАН** Степень созревания, готовности льна после вылёживания на мокрой земле (стебли льна смягчаются и волокна от них отделяются) для дальнейшего процесса обработки и сушения на солнце, в бане или в сушилке. – *Җитенне, булсын дип, дымлы урыннарга җәяләр, булуы җиткәч, җыеп, мунчада киптерәләр.*

**ҖИТЕН БУЛДЫРУ** *к.* **җитен җәю**.

**ҖИТЕН ҖӘЮ** Постилка льна для смачивания (для разложения и удаления вещества, склеивающегося волокна).

**ҖИТЕН ҖӘЮ УРЫНЫ** Стлище; место, где расстилают лён.

**Җитенне чыкка җәю** Постилка льна на росу (росистую траву).

**ҖИТЕН ҖЫЮ** *к.* **җитен алу**.

**ҖИТЕН ИГҮ** Выращивание, возделывание льна.

**ҖИТЕН ЙОЛКУ // ҖИТЕН ҖОЛКУ** *Үтәг.-Әг., Каз.ар.* Уборка льна с полей, вырывая его с корнями. – *Җитенне берәмләп җолыктык.*

**ҖИТЕН КӨЛТӘСЕ** Сноп из нескольких (от двух до шести) горстей льна. – *Берәр уч итеп көлтәләгән җитен көлтәсе дә була.*

**ҖИТЕННЕ ҖӘЮ** *к.* **җитен җәю**.

**ҖИТЕННЕ КӨЛТӘГӘ БӘЙЛӘҮ** *к.* **көлтәләү**.

**ҖИТЕННЕ КИПТЕРҮ** Сушка льна.

**Җитенне көндә киптерү** Сушка льна на открытом воздухе.

**Җитенне мунча киштәсенә күтәреп киптерү** Сушка льна на специально устроенных полках – сушилках.

**ҖИТЕННЕ МУНЧА КИШТӘСЕНӘ КҮТӘРҮ** *к.* **җитенне мунча киштәсенә күтәреп киптерү**

**ҖИТЕННЕ СУГА САЛУ** *Каз.ар., Бал., К.Черк.-Буа* Вымачивание льна в воде.

**ҖИТЕННЕҢ БУЛУЫ ҖИТҮ** Достаточное время вымачивания льна для дальнейшей обработки.

**ҖИТЕННЕҢ ӨЛГЕРЕШЕ** Зрелость льна.

**Җитеннең иртә сары өлгереше** Ранняя жёлтая зрелость льна.

**Җитеннең сары өлгереше** Жёлтая зрелость льна.

**Җитеннең тулы өлгереше** Полная зрелость льна.

**Җитеннең яшел өлгереше** Зелёная зрелость льна, молочная зрелость.

**ҖИТЕН ОРЛЫГЫ** Семя льна.

**ҖИТЕН ОРЛЫГЫН АЛУ** Молотить, обмолотить семена льна (отделить семена от стеблей путем околачивания, обмолота головок).

**ҖИТЕН ӨЗҮ** *К.Черк.-Буа к.* **җитен алу**.

**ҖИТЕН САБАГЫ** Стебель льна.

**ҖИТЕН СӨЯГЕ** *Янт.-Ла.* Кострика; измельчённый стебель льна после трепания.

**ҖИТЕН ТАЛКУ** Трепать, мять, теребить лён мялкой. – *Җитен талкысаң, сүсе була.*

**ҖИТЕН УЧМАСЫ** 1. Горсть льна, горстка льна. 2. Способ укладки льна для сушки.

**ҖИТЕН ЧӘЧҮ** Посев льна.

**ҖӨГЕРҮ** *Мөс.-Чист.* Образование излишки пряжи основной нити, оставшейся при проборке в бердо. – *Кылыч тешләренә караганда артыграк озатылса, җепнең җөгерүе килеп чыга.*

**ҖӨГЕРЧЕК // ҖЕГЕРЧЕК** *Бах.-Чист.* Излишки нитей основы, остающиеся после заправки берда при несоответствии номера длины берда; *к.* **колынчак**. – *Җөгерчек – кылычтан артып калган җеп (ялгыш яки тиешле кылыч булмаганда мәҗбүри рәвештә артык озатылган җеп). – Артык өлеш җөгерчек дип атала.*

**ҖӨЙ // ҖЕК** Шов, след шва от соединяемых двух одинаковых кусков ткани.– *Ашаулык ике кисәктән торса, ялгаган җекләре беленмәслек булсын.*

**ҖӨРӘКЧӘ** *К.Ач.-Я.Уз.* Приспособление из дощечки с двумя дырочками, употребляющееся при перемотке нитки с вороба на сучило.

**ИҢ** Ширина (ткани, холста, берда).

**ИҢ ҖЫЮ** *Исәнб.-Әг.* Брак, погрешность в процессе тканья, когда ширина сужается из-за натяжения уточных нитей.

**ИҢНӘҮ** *Тәт.* Растягивание ткани с двух сторон по ширине для последующего измерения длины.

**ИРҮ** *Саб. к.* **эрләү**.

**ЙОН // ҖОН** Шерсть, руно. – *Сүзне сүзгә тоташтырсаң – ип булыр; йонны йонга тоташтырсаң – җеп булыр* (Мәкаль).

**ЙОМГАК** Клубок. – *Йон йомгагым − бөдерә, Су күрдеме – йөгерә (Үрдәк бәбкәсе)* (Табышмак). – *Идән җәймәсенең аркавын йомгакка чорныйсың.*

**ЙӨГЕРТҮ** *Чал.-К.Там., К.Бөк.-Б.Бист. к.* **аркау ату**. – *Кызыл арасына ак йөгертәсең.*

**ЙӨЗЕК КАШЫ** *Кук., Ар., Балт.* Круглые узоры величиною с копейку, полученные при тканье браным способом белыми нитями на двух дощечках. – *Ак чүпләм бизәгенең берсен йөзек кашы диләр.*

**ЙӨРҮ // ҖӨРҮ** *Т.Тәк.-Минз.* Частое применение понравившегося орнамента. – *Матур бизәк күп җөри.* – *Бу бизәк җөриячәк инде хәзер дип уйлаем.*

**КАБА** Прялка, пряслице, прялица; орудие для ручной пряжи, состоящее из шестика и донца, к гребню которого прикрепляется волокно при прядении на веретене. – *Каба тараклы да, таяклы гына да була.*

**Җеп кабасы** *к.* **таяклы каба**.

**Җон кабасы** *Тирс.-Әг.* Прялка с лопастью (с лопаточкой).

**Җөй кабасы** *Мөс., Бах.-Чист.* Приспособление для ручного шитья, похожее на прялку.

**Калаклы каба** *к.* **җон кабасы**.

**Очлыкый каба** *к.* **җон кабасы**.

**Тамыр каба** Цельная прялка, донце и шестик которой сделаны из корня дерева.

**Тараклы каба** Прялка с гребнем и шестиком, воткнутым на донце.

**Таяклы каба** Прялка с палочкой (без лопатки), иногда без донца.

**Тәрәшле каба** *к.* **тараклы каба**.

**Үзәк кабасы** *Исәнб.-Әг. к.* **тараклы каба**.

**КАГАЙТУ** *Чал.-К.Там.* Подсушка конопли и льна для последующего трепания.

**КАГУ** Встряхивание волокна, льна и конопли; *чаг.* **талку**.

**КАЗ ТӘНЕ** *Ям.-Б.Бист., И.Кен., Кышк.-Ар.* Способ тканья в две доски.

**КАЙТАРУ** *Кел.-К.Там., О.Тар.-Тәт.* При браном способе тканья способ симметричного убавления узора с середины (при плетении лаптей первым слоем лыка). – *Бизәкнең яртысына кадәр чүпләү була, яртысыннан соң – кайтару.*

**КАЙЧЫЛЫК** Деталь берда; набилки, подвижная рама в ткацком станке, в которую вставляется бердо, для прибивания уточной нити к ткани.

**КАККЫЧ** Трепальная машина; *к.* **талкы**.

**КАЛАК** 1. *И.Шәй.-Чүпр., К.Черк.-Буа* Щепочка, тонкая дощечка для выбора нитей на основе для получения добавочного зева при узорном тканье браной и закладной техниками; *к.* **чүпләм таягы**, **чәбе**. – *Калак җеп чүпли торган чыра* (К.Черк.-Буа). – *Аркау җеп чолгаган юка такта калак була.* (И. Шәй.-Чүпр.). 2. *О.Тар.-Тәт.* Дощечка, подкладываемая под выбранные нити.

**КАЛАК КҮТӘРҮ** *к.* **такта күтәрү**. – *Кешегә калак күтәрдерием, бер йомырка бирәләрие.*

**КАЛТЫРЧА** *Саб., Кук., Ар.* // **КАЛДЫРЧА** *Курм.-Нурл., О.Тар.-Тәт., К.Черк.-Буа* Скальница, сучило (приспособление для наматывания цевок). – *Калтырча белән шүре ясыйсың.* – *Калдырча – җепне шүрегә чолгый торган кирәк-ярак.*

**КАМФАРКА** *Алп.* (> *рус.* **конфорка**) Браный узор, со специально заложенными дырками.

**КАНДАЛА КАБЫГЫ** *Ю.Пош., И.Кен.-Ар., Бал., К.Там.* «Клоп», узор браного тканья в одну или две доски, напоминающий узор современных вафельных полотенец; *к.* **такта чүпләм**. – *Мунча җәймәсе кандала кабыгы белән сугыла, хәзерге шадра сөлгеләр шикелле була.*

**КАПТЫРМА** *У.Кирм.-Мам., О.Тар.-Тәт.* Запор, застёжка пришвы ручного ткацкого стана.

**КАРА** *Шәле-Пит.* // **КАРЫ** *Бах., Мөс.-Чист.* Мера для измерения длины ниток в пасме, в мотовиле (в разных местах означал разную длину: в селе Шали из 4, 5, 6 аршинов, в селах Бахта, Муслюмкино Чистопольского района – длину локтя, т.е. от локтя до конца среднего пальца).

**КАРА МӨШКӘ** *к.* **баса**.

**КАРА ПӘҖИ** *к.* **баса**.

**КАРЕ́ТКА** *Каз.* Деталь льночесальной машины.

**КАРТАЛЫ БУЛУ** *У.Пош.-Ар.* Неровности, образующиеся вследствие прибивания бердом различной силой (о деффекте холста).

**КАТКЫЧ** *Мам., Тәт.* 1. Веретено с пряслицей для сучения ниток. 2. Сучило, скально, крутило (орудие для мотания цевок, напоминающее веретено с пряслицей).

**КАТУ** Сучение, кручение двух или более ниток.

**Сүлпән кату** Слабое сучение.

**Чирак кату** Крутое сучение.

**КАТМА** *к.* **каткыч**.

**КАТЫЛУ** Особенность, способ сучения, кручения.

**КАТЫМ** *к.* **катылу**.

**КАШАГА** Занавес, который закрывает стены поверх окон, матицу на потолке, верхнюю часть печи и т.п.

**КАШЫК** *к.* **әвернә кашыгы**.

**КӘКРЕ КУЛ** *Шәле-Минз., Мам. к.* **тубырча**.

**КЕЛӘНЧЕ** *Кар.-К.Там., О.Тар.-Тәт.* // **КЕЛӘНЦЕ** *Чүпр. к.* **чүпләм таягы**. – *Кылыч саплый торган юка гына ыргаклы агач келәнче була.*

**Чүпләм келәнчесе** *Кар.-К.Там.* 1. *к.* **чүпләм чыбыгы**. 2. *к.* **кылыч инәсе**. – *Кылыч теше зуррак булса буйлык җепне чүпләм келәнчесе урынына бал кашыгы сабы белән дә аласың.*

**КИЕРГЕ** 1. *Саб. к.* **озаткыч**. 2. *Бах.-Чист., Мәлк.-Минз., З.Кул.-Б.Бист.* Распялка; палочка для натягивания вытканного холста (вкладывается в продольную щель пришвы). 3. *Мәлк.-Минз. к* .**бавыр агачы**.

**Җеп озату киергесе** Рамочная сновальня, сновалка, состоящая из четырехугольной рамы длиной 3–3,5 м и шириной 80–90 см, на торцах рамы прибиты колышки по три на каждом противоположном торце, на раме вбиты еще 2 колышка.

**КИЕРГЕ ТАЯГЫ** *Мәлк.-Минз.* Распялка для натягивания тканого паласа-ковра.

**КИҖЕ** (> *перс.* **кажи** «необработанный шелк») 1. Хлопчатобумажная нитка фабричного прядения. 2. Хлопчатобумажная нитка красного цвета. – *Кижҗе лә күлмәк, аллар итәк, Киче, туганым, тузганчы. Кеше туганнары, бакчи, ничек, Ташлашмыек, туганым, үлгәнче* (Хал. җыры).

**КИҖЕЛЕ** Вперемежку, с использованием хлобчатобумажной нитки преимущественно красного цвета. – *Буена төрле төстәге*: *күк, сары, ак, кызыл мамык җепләре куеп, вак шакмаклап күлмәк кияриек, кижҗеле күлмәк дип йөртәдериек.*

**КИҖЕ-МАМЫК** Хлопчатобумажный. – *Кижҗе-мамык тукыма.*

**КИЛӘП** *Каз.ар., Чүпр., Бик.-Нурл.* // **КИЛӘФ** *Троян.* // **КӘЛӘП** *Кук.* (> *перс.* **калаба**, **калаб** «моток, пряжа, клубок»). Моток, мотушка, пряжа, намотанная широкими кругами для беления, окраски или определения длины. – *Өчәр басмалы киләпләр була, кирәкчә озатасың. – Элек кара һәм кызыл кәләпле дебет буладырые.*

**Озын киләп** *Чүпр.* Длинный моток, мотовило.

**КИЛӘП АГАЧЫ** *У.Пош.-Ар., Саб., Сал., Тирс.-Әг., Нор.-Я. Үз., И.Тинч.-Буа* Мотовило; приспособление для сматывания и разматывания мотков пряжи в виде палки с крестообразным разветвлением на одном, с поперечиной на другом конце, или с поперечинами на обоих концах. – *Киләп агачының биш чиреклесе, җиде чиреклесе була, дүртәүләп саныйлар – 60 савым бер басма* (Сал.-Әг.).

**КИЛӘП АГАЧЫНА САРУ** *Минз. к.* **киләп сару**.

**КИЛӘПКӘ САЛУ** *И.Кыяз.-Акс. к.* **киләп сару**.

**КИЛӘП ПЕШЕРҮ** *И.Шәй.-Чүпр.* Кипячение пряжи в щёлочи.

**КИЛӘП САВЫМЫ** *У.Балт.-Ап., Кыр.-Әг.* Чисменка из моталки в 4 нитки.

**КИЛӘП САРУ** *Каз.ар., К.Черк., Килд.-Буа, И.Шәй.-Чүпр.* Перематывание напряденных ниток с веретён или со шпулек в мотки (мотание выполняется мотовилом или упрощенно: на стенку или ножки стула, через углы стола или скамьи).

**КИЛӘПТӘН ТӨШЕРҮ** *Мам., Каз.ар., Тирс.-Әг.* Снятие мотка с мотовила, слегка растягивая. – *Киләптән төшерү өчен, киләпне баскалап, сузылдырып бушайтасың.*

**КИЛӘФ САБЫ** *Троян. к.* **киләп агачы**.

**КИЛӘПЛӘҮ** *к.* **киләп сару**.

**КИЛЕ // КӨЙЛЕ** Ступа; высокая деревянная напольная посуда для толчения волокна и т.п.

**КИЛЕ БАШЫ** *Кадр.-Әг. к.* **киле сабы**.

**КИЛЕ САБЫ** Пест. – *Килгән җире киләп җебедәй, килмәгән җире киле сабыдай* (Мәкаль).

**КИЛЕСАП** *к.* **киле сабы**.

**КИЛТӘ** (> *перс.* **короткий**) *Үтәг., Исәнб.-Әг., Мәлк.-Минз.* // **ПИЛТӘ** *Мәлк.-Минз.* Концы основы, оставшиеся после отрезания вытканного холста (длиной с вершок). – *Арсаң, ярты метр килтә калдырып та кисәсең, аның өчен әниләр орыша – җепне әрәм итәсең дип. – Киндер бетергәндә тияккә тыгып бетерәсең киндерне, җебе бер генә карыш кала. Баш-башларын бәйлисең, килтәсен кисеп аласың. – Киндерне бетерү алдыннан көрегә керми калган буй җеп очлары килтә була. – Сукканнан соң калган җеп пилтә була.*

**Җиле килтәсе** *Кук., Я.Үз. к.* **җил җебе**. – *Җиле килтәсе – озатканда җиле турысына куелган бау.*

**Җилен килтәсе** *Нор., Тау и.-Я.Үз. к.* **басма бавы**.

**Килтә җебе** *Үтәг., Исәнб.-Әг., Минз., Ар. к.* **килтә**.

**КИНДЕР** 1. Конопля; высокое однолетнее растение южного сорта с мощным стеблем. 2. Кендырь; сорт конопли: многолетнее волокнистое растение. – *Киндер чәчсәң, күлмәк киярсең* (Мәкаль). 3. Полотно, холст. 4. *О.Кар.-К.Там.*

Белое полотно, белый холст. – *Акка тук , печмәгә киндере юк* (Мәкаль).

**Алача киндер** *к.* **алача**. – *Шаламаны җәйдем, Аламаны телдем, Алача киндер тукыдым (Чабата үрү)* (Табышмак).

**Алма чүпләмле киндер** *к.* **алмалы киндер**.

**Алмалы киндер** Пестрядь, холст с разноцветными узорами, вытканный браным способом.

**Ашлаган киндер** *к.* **ашлы киндер**.

**Ашлы киндер** Шлихтованный холст.

**Ашламаган киндер** Суровьё, суровый холст, нешлихтованный холст.

**Баса киндере** 1. Посконь (мужские стебли конопли). 2. Посконный холст, посконина.

**Баскан киндер** *к.* **басма киндер**.

**Басма киндер** Крашеный холст с узором, нанесённым особым способом крашения – завязывались узлы, в которые краска не проникала (предназначался для наволочек, мужского и детского белья).

**Биш көреле киндер** *Мам.* Холст, вытканный в пяти нитченках и соответственно на пяти подножках белыми нитками утка и основы.

**Дүрт көреле киндер** *Мам.* Холст, вытканный на четырёх подножках, в четыре нитченки, белыми нитками основы и утка. – *Дүрт көреле киндер буйлы ак товар була бит.*

**Җеп киндер** *Шәле-Пит.* Холст из льняных ниток.

**Җитен киндере** Льняное полотно.; *к.* **китән**. – *Җитен киндер ай яктысында агара имеш* (Мәкаль).

**Мамык киндер** *Бал.* Хлопчатобумажное полотно. – *Егетләргә җиде иң мамык киндердән ак алҗапкыч тегәләр, бавына матур тасма тагалар.*

**Орлык киндере** 1. Матерка, конопля с семенами, зёрнами, женские стебли конопли, дающие семена (их убирают с поля после созревания семян осенью, волокно поэтому грубее). 2. Холст из этой конопли.

**Рәт киндер** Холст, вытканный основным полотняным способом тканья (когда каждая нить утка переплетается с каждой нитью основы на двух нитченках и двух подножках), рядно; **прощиня** (*диал. Полесье*). – *Рәт киндер ике рәтләндереп, ике көре белән генә, бизәкләмичә суккан киндер.*

**Сүс киндере** *к.* **баса киндере**.

**Төз киндер** *к.* **рәт киндер**.

**Тула киндере** *К.Бөк.-Б.Бист.* Суконный холст, сукно, вытканное из шерстяных ниток.

**Туры киндер** *Бал. к.* **рәт киндер**.

